**Республика Татарстан**
**Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге**

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**от 20.03.2024 г.** **№ 2**

«Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Карашай-Саклау авылы, Ленин урамы, 100 йорт адресы буенча урнашкан Карашай-саклау авылы мэдэният йортында «Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

« Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр

элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Чураш торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)ремонтлау;
2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Чураш торак пунктында су өчен савытлар сатып алу);
3. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Чурашево торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чураш торак пунктында җәйге вакытта территорияне кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, Чураш торак пункты паркын саклау)?»;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районының
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы /В.В.Хосниева/